**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**15-РС** **2019 елның 3 апреленнән**

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының
территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр
кертү проектын әзерләү турында**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясенең тотрыклы үсешен, шәһәр төзелеше һәм инвестиция эшчәнлегенең, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктуралар үсешен тәэмин итү максатында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 10, 18-21 маддәләренә, 2003 елның 6 октябреннән № 131-ФЗ "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль законның 15 маддәсенә, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июленнән №45-ЗРТ "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы законының 16 маддәсенә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставының 45, 49 маддәләренә ярашлы төстә, муниципаль берәмлекнең икътисади үсеше максатында, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль район Советы **карар бирде**:

1. Район Советының 2011 елның 19 декабреннән №117-РС карары белән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының "Челтәр компания" ЧҖҖ электр белән тәэмин итү объектлары өлешендә территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын әзерләүгә керешергә.
2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына (архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге) Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмати системасында https://fgistp.economy.gov.ru/ веб-адресы буенча урнаштырылуын тәэмин итәргә.
3. Бу карарны "Камская новь" ("Кама ягы") газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы һәм Лаеш муниципаль районы рәсми сайтының Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырырга (халыкка чыгарырга).
4. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне район Башкарма комитеты җитәкчесе М.В.Фадеевка йөкләргә.

**Башлык - муниципаль район Советы
рәисе вазифаларын башкаручы** **Т.П.Бурганова**